ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_29_»___05____2026 ел № 583

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су түгү өлкәсендә гарантияләүче оешманы билгеләү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында»гы 07.12.2011 № 416-ФЗ Федераль законы, "Җылылык белән тәэмин итү турында"гы 27.07.2010 ел, № 190-ФЗ Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә өзлексез җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне, су агызуны оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасының "Электр челтәрләре" дәүләт унитар предприятиесен (ОГРН 1051641034807, ИНН 1660079256) түбәндәгеләр белән билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләүче оешма статусы белән;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының түбәндәге торак пунктлары территориясендә су белән тәэмин итү һәм су түгү өлкәсендә гарантияләүче оешма статусы белән: Әбсәләм авылы, Димтамак авылы, Ак Юл авылы, Алабакүл авылы, Тарлау авылы, Урыссу штб, Байлар авылы, Ютазы авылы, Ык авылы, Ютазы кымыз дәваханәсе бистәсе.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Е.С. Огнева
2-42-19